ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

22 февраль, 2017 ел № 15/10

Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында

Шәһәр Советының «Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» карар проекты буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен карап тикшергәч, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ санлы Федераль законның 28, 44 маддәләре, Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 92, 93, 94 маддәләре нигезендә
Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге вәкиллекле органының 2005 елның 8 декабрендәге 6/5 санлы Карары белән расланган (Шәһәр Советының 2006 елның 19 октябрендәге 15/4, 2007 елның 4 июлендәге 23/4, 2007 елның 25 декабрендәге 28/10, 2008 елның 29 февралендәге 30/7, 2009 елның 9 апрелендәге 40/6, 2009 елның 10 сентябрендәге 42/7, 2010 елның 31 мартындагы 47/7, 2010 елның 27 декабрендәге 7/6, 2011 елның 15 декабрендәге 15/7, 2012 елның 5 июлендәге 19/15, 2012 елның 20 декабрендәге 22/19, 2013 елның 29 августындагы 26/17, 2014 елның 21 февралендәге 29/17, 2014 елның 16 октябрендәге 33/17, 2015 елның 27 февралендәге 38/14, 2015 елның 23 июлендәге 41/11, 2016 елның 24 февралендәге 6/10 санлы Карарлары редакциясендә) Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) **9 маддәнең 1 өлеше 13 пунктында** «каникул вакытында балаларның ялын оештыру» сүзләрен «үз вәкаләтләре чикләрендә каникул вакытында балаларның ялын оештыруны тәэмин итү буенча чараларны гамәлгә ашыру, аларның тормышлары һәм сәламәтлекләре куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча чараларны кертеп» сүзләренә алыштырырга;

2) **9.1 маддәсенең 1 өлешенә** түбәндәге эчтәлектәге **16 пунктны** өстәргә:

«16) хокук бозуларны кисәтү өлкәсендә «Россия Федерациясендә хокук бозуларны кисәтү системасы нигезләре турында» Федераль закон белән каралган чараларны гамәлгә ашыру;»;

3) **31 маддәнең 7 өлеше 2 абзацын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Даими нигездә шәһәр Хакиме һәм муниципаль берәмлек Башлыгы урынбасары эшли.»;

4) **34 маддәнең 2 өлешендә** «хәлиткеч тавыш бирү хокукы белән» сүзләрен төшереп калдырырга;

5) **36 маддәнең 2 өлешен** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Шәһәр Хакименең вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракта яисә аңа карата суд карары буенча сак астына алу рәвешендә процессуаль мәҗбүр итү чаралары кулланылганда яки вакытлыча вазифадан читләштерелгәндә, аның вәкаләтләрен үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы муниципаль берәмлек Башлыгы урынбасары вакытлыча башкара.»;

6) **40 маддәнең 5.1 өлешен** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.1. Башкарма комитет Җитәкчесенең вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракта яисә аңа карата суд карары буенча сак астына алу рәвешендә процессуаль мәҗбүр итү чаралары кулланылганда яки вакытлыча вазифадан читләштерелгәндә, яңа Башкарма комитет Җитәкчесен билгеләү турында Шәһәр Советы карары кабул ителгәнчегә кадәр, аның вәкаләтләрен шәһәр Хакиме тарафыннан билгеләнгән зат башкара. Шәһәр Советы чираттагы утырышта Башкарма комитет Җитәкчесе вакантлы вазифасын биләүгә конкурс игълат итү турында карар кабул итә.»

7) **41 маддәдә:**

- 3 өлешне түбәндәге эчтәлектә бәян итәргә:

«3. Әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигый ресурслардан файдалану өлкәсендә:

1) экологик торыш турында халыкка хәбәр итү, табигый бәла-казалар, һәлакатләр очрагында халык куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча чаралар күрү;

2) муниципаль экологик программалар һәм чаралар эшләү, гамәлгә ашыру, аларның үтәлешен контрольдә тоту;

3) шәһәр атмосферасы пычрануы, өслектәге сулыкларга пычрак агызу, туфракның пычрануы, калдыкларны урнаштыру торышы турында мәгълүматларны исәпкә алу һәм анализлау;

4) әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә хокук бозуларны ачыклау, кисәтү һәм булдырмау буенча чараларны тормышка ашыру;

5) муниципаль берәмлек территориясендә хуҗалык итүче субъектлар тарафыннан башкарылган табигатьне саклау чараларына анализ;

6) җир асты байлыкларын файдалануга биргәндә һәм җир кишәрлекләрен бүлеп биргәндә, территория халкының социаль-икътисадый һәм экологик мәнфәгатьләрен үтәү белән бәйле мәсьәләләрне хәл итүдә катнашу;

7) гомумтаралган файдалы казылмаларны чыгарганда, шулай ук файдалы казылмаларны чыгару белән бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзегәндә, җир асты байлыкларыннан файдалануны һәм саклауны контрольдә тоту;

8) экологик экспертиза объектларына дәүләти экологик экспертиза эксперт комиссияләре утырышларында күзәтүче сыйфатында катнашу өчен экспертлар җибәрү, әлеге объектларны тиешле территориядә реализацияләгән очракта һәм башка административ-территориаль берәмлек күздә тоткан хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохиткә мөмкин булган йогынтысы очрагында;

9) үз вәкаләтләре чикләрендә җәмәгать фикер алышулары, сорашулар, референдумнар, экология оешмаларының (берләшмәләренең) һәм хәрәкәтләренең

гаризалары нигезендә экологик экспертиза сораулары буенча карарлар кабул итү һәм тормышка ашыру;

10) экологик экспертиза үткәрелергә тиешле күздә тотылган хуҗалык һәм башка эшчәнлек турында халык арасында җәмәгать фикер алышулары, сорашулар, референдумнар уздыру;

11) халык таләбе буенча иҗтимагый экологик экспертизалар оештыру;

12) экологик экспертиза өлкәсендә башкарма хакимиятнең федераль органнарына тиешле муниципаль берәмлек территориясендә күздә тотылган хуҗалык яисә башка эшчәнлек турында хәбәр итү;

13) прокуратура органнарына, әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә башкарма хакимиятнең федераль органнарына һәм Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнарына экологик экспертиза объектын гамәлгә ашыру башлануы турында дәүләт экология экспертизасының уңай бәяләмәсеннән тыш хәбәр итү;»;

**- 7 өлешкә** түбәндәге эчтәлектәге **22, 23, 24, 25, 26, 27 пунктларны** өстәргә:

«22) террорчылыкны профилактикалау, шулай ук аның күренешләре нәтиҗәләрен минимизацияләү һәм (яки) ликвидацияләү өлкәсендә муниципаль программаларны эшләү һәм тормышка ашыру;

23) террорчылыкның асылын һәм аның иҗтимагый куркынычын аңлату буенча, шулай ук гражданнарда террорчылык идеологиясенә каршылык формалаштыру буенча мәгълүмати-пропаганда чараларын оештыру һәм үткәрү, шул исәптән мәгълүмати материаллар, басма продкуция тарату, аңлату эшләре алып бару һәм башка чаралар уздыру юлы белән;

24) башкарма хакимиятнең федераль органнары һәм (яки) Россия Федерациясе субъектының башкарма хакимият органнары тарафыннан оештырылган террорчылыкны профилактикалау, шулай ук аның күренешләре нәтиҗәләрен минимизацияләү һәм (яки) ликвидацияләү буенча чараларда катнашу;

25) муниципаль берәмлектә булган яки җирле үзидарә органнары карамагындагы объектларның террорчылыкка каршы саклануына таләпләрнең үтәлешен тәэмин итү;

26) Россия Федерациясе субъектының башкарма хакимият органнарына террорчылыкны профилактикалауда, шулай ук аның күренешләре нәтиҗәләрен минимизацияләүдә һәм (яки) ликвидацияләүдә катнашу мәсьәләләре буенча тәкъдимнәр җибәрү;

27) террорчылыкны профилактикалауда, шулай ук аның күренешләре нәтиҗәләрен минимизацияләүдә һәм (яки) ликвидацияләүдә катнашу буенча җирле билгеләнештәге мәсьәләләрне хәл итү буенча башка вәкаләтләрне башкару.»;

- **8 өлешкә** түбәндәге эчтәлектәге **9 пунктны** өстәргә:

«9) хокук бозуларны кисәтү өлкәсендә «Россия Федерациясендә хокук бозуларны кисәтү системасы нигезләре турында» Федераль закон белән каралган чараларны гамәлгә ашыру;»;

- **9 өлешнең 25 пунктын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«25) җирле билгеләнештәге автомобиль юллары буенча хәрәкәт иткәндә авыр үлчәүле транспорт чаралары китергән зыянның күләмен билгеләү;».

- **11 өлешкә** түбәндәге эчтәлектәге **14 пунктны** өстәргә:

«14) Башкарма комитетның муниципаль хокукый акты нигезендә эшмәкәрлек һәм инвестиция эшчәнлеге субъектлары өчен яңа бурычларны билгеләүче яки

муниципаль норматив хокукый актлар белән электән каралган бурычларны үзгәртүче муниципаль хокукый акт проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне үткәрү, законнар белән билгеләнгән очраклардан тыш;»;

- **14 өлешкә** түбәндәге эчтәлектәге **7 пунктны** өстәргә:

«7) үз вәкаләтләре чикләрендә каникул вакытында балаларның ялын оештыруны тәэмин итү буенча чараларны гамәлгә ашыру, аларның тормышлары һәм сәламәтлекләре куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча чараларны кертеп;»;

8) **XII бүлекнең** исемендә «һәм муниципаль вазифалар» сүзләрен өстәргә;

9) **XII бүлеккә** түбәндәге эчтәлектәге **48.1 маддәсен** өстәргә:

«48.1 маддә. Яр Чаллы шәһәре җирле үзидарә органнарында, муниципаль органнарда муниципаль вазифалар биләүче затлар

1. Муниципаль вазифаларны биләүче затлар булып Шәһәр Советы депутатлары, шәһәр Хакиме, Контроль-хисап палатасы рәисе, Сайлау комиссиясе рәисе тора.

2. Муниципаль вазифаларны даими нигездә биләүче затларга шәһәр Уставының 48 маддәсе 7 өлеше белән каралган өстәмә гарантияләр бирелә. Өстәмә гарантияләр бирү тәртибе һәм шартлары Шәһәр Советы карары белән билгеләнә.»;

10) **50 маддәгә** түбәндәге эчтәлектәге **5.1 өлешен** өстәргә:

«5.1 Эшмәкәрлек һәм инвестиция эшчәнлеге субъектлары өчен яңа бурычларны билгеләүче яки муниципаль норматив хокукый актлар белән электән каралган бурычларны үзгәртүче муниципаль норматив хокукый акт проектларының җайга салу йогынтысы җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы законы нигезендә бәяләнергә тиеш, Шәһәр Советының җирле салымнарны һәм җыемнарны билгеләүче, үзгәртүче, туктатып торучы, юкка чыгаручы норматив хокукый актлары проектларыннан, шулай ук Шәһәр Советының бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга салучы норматив хокукый актларыннан тыш.

Муниципаль норматив хокукый акт проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү эшмәкәрлек һәм инвестиция эшчәнлеге субъектлары өчен артык вазифаларны, тыюларны һәм чикләүләрне кертүче яки аларны кертергә ярдәм итүче нигезләмәләрне, шулай ук эшмәкәрлек һәм инвестиция эшчәнлеге субъектларының һәм шәһәр бюджетының нигезләнмәгән чыгымнары барлыкка килергә ярдәм итүче нигезләмәләрне ачыклау максаты белән үткәрелә.»;

11) **92 маддәнең 2 абзацын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Шәһәр Уставына Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Татарстан Республикасы Конституциясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезләмәләрен төгәл күрсәтү рәвешендә үзгәрешләр кертелгәндә, шәһәр Уставын әлеге норматив хокукый актларга тәңгәлләштерү макстында, шәһәр Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый акт проекты буенча тәкъдимнәрне исәпкә алу тәртибен, шулай ук аның буенча фикер алышуларда гражданнарның катнашу тәртибен рәсми бастыру (халыкка җиткерү) таләп ителми.».

2. Әлеге Карар матбугатта рәсми басылган көннән үз көченә керә, нигезләмәләр өчен үз көченә керү гамәлдәге законнар белән башка вакытта каралган.

3. Яр Чаллы шәһәре Хакиме Н.Г. Мәһдиевкә әлеге Карарны гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә юнәлтергә.

4. Әлеге Карар үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының регламент, хокук тәртибе, законлылык һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсе тарафыннан 2017 елның 23 мартында теркәлгән. Дәүләти теркәү номеры № RU 163020002017001.